РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
ЧЕРКИ-КИЛЬДУРАЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛЬДУРАЗ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 05 » март 2018 г. № 1-50

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Кильдураз авыл җирлегендә гражданнарның
мөрәҗәгатен карау Регламентына
үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруда гомуми принциплар турында”гы 2003 нче елның 06 нчы октябрь № 131 –ФЗ, “Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатен карау тәртибе турында” 2006 нчы елның 02 нче май №-59 ФЗ,”Федераль Законга үзгәрешләр кертү турында “Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатен карау тәртибе турында” 2017 нче елның 27 нче ноябрь № 355 –ФЗ Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кильдураз авыл җирлеге Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кильдураз авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кильдураз авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатен карау регламентын раслау турында”гы 2014 нче елның 23 нче октябрь № 1-50 карары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кильдураз авыл җирлеге Советында расланган гражданнарның мөрәҗәгатен карау Регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.3 нче бүлектә:

3.4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.4 Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи зат исеменә электрон документ аша килгән мөрәҗәгать “Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатен карау тәртибе турында” 2006 нчы елның 02 май № 59-ФЗ Федераль Закон кабул иткән тәртиптә карала. Гражданин үзенең мөрәҗәгатендә мәҗбүри рәвештә фамилиясен, исемен, әтисенең исемен(булган очракта), җавап җибәрелергә тиеш электрон адресын күрсәтә, яшәү урынын алмаштырган очракта, адресы үзгәрү турында хәбәр итә. Гражданин мондый мөрәҗәгатькә электрон формада кирәкле документларны һәм материалларны өсти ала

1.2 4 нче бүлектә:

4.1.пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.1 Мөрәҗәгать каралмый, әгәр:

1) гражданин үзенең мөрәҗәгатенә берничә тапкыр язма рәвештә җавап алган булса һәм яңа дәлилләр, өстәмәләр китерелмәсә, шулай ук мөрәҗәгатьләр бер үк органга һәм бер үк вазыйфаи затка юлланган булса;

1.1) җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать килгән очракта, җавабы 2006 нчы елның 02 май № 59-ФЗ “Россия Федерациясендәге гражданнарның мөрәҗәгатен карау тәртибе”Федераль законның 10 нчы статьясы 4 нче бүлегендә урнаштырылган “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге әлеге җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырылган булса, мөрәҗәгать итүче гражданинга 7 көн эчендә “Интернет” мәгълүмати – коммуникацион челтәренең рәсми сайтының электрон адресы хәбәр ителә, әмма суд карарына риза булмыйча шикаять бирү мөрәҗәгате кире кайтарылмый;

2) язма мөрәҗәгатьнең тексты укылырга тиеш түгел;

2.1) язма мөрәҗәгатьнең тексты гариза, тәкъдимнәр, шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинчелек бирмәсә, җавап бирелми һәм дәүләт, җирле үзидарә органнарында да, вазыйфаи зат тарафыннан да каралмый һәм бу турыда 7 көн эчендә мөрәҗәгать итүче гражданга җавап бирелә;

3) мөрәҗәгатьтә каралган сораулар буенча, үз көченә кергән суд карары булганда;

4) вазыйфаи затның тормышына, сәламәтлегенә, мал – мөлкәтенә, гаилә әгъзаларына карата куркыныч янап кулланылган кимсетү, кыерсыту сүзләре булганда;

5) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе һәм адресы күрсәтелмәгәндә;

6) Федераль закон һәм дәүләт тарафыннан сер итеп тотылган мәгълүматка кагылышлы җавап булганда.

Гражданның сорауларына элек җавап бирелгән булса, шәхси кабул итү вакытында аның мөрәҗәгате каралмый.

Ниндидер сәбәпләр аркасында мөрәҗәгать итүченең сораулары канәгатьләндерелмәгән булса, граждан яңадан үзенең мөрәҗәгатен тиешле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яки вазыйфаи затка юллый ала.

1.3.7 нче бүлектә:

7.8.1пунктның 7.8 бүлеген үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«7.8.1 Мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органы җитәкчесе ,вазыйфаи зат яки вәкаләтле вәкил тарафыннан имзалана.”

7.8.2 пунктның 7.8 бүлеген үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«7.8.2 Җавап төгәл, кыска, эзлекле булырга , хатта бирелгән сорауларга тулы аңлатма бирелергә тиеш. Шикаятьтәге фактлар расланганда, гражданның мөрәҗәгате буенча нинди чаралар күрелүе әйтелә.»

Җавап җирле үзидарә органына яки вазыйфаи зат исеменә җибәрелгән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон адреска электрон документ формасында һәм язма формада аның яшәү буенча күрсәтелгән адресына җибәрелә. Аннан башка җирле үзидарә яки вазыйфаи затка юлланган мөрәҗәгатьтә чикләнмәгән затлар даирәсенең мәнфәгатьләренә кагылышлы тәкъдимнәр, гариза, шикаятьләр булганда, шулай ук аларга кагылышлы суд карары чыгарылган очракта, җавап яки суд карары буенча шикаять бирү тәртибе “Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатен карау тәртибе турында” 2006 нчы елның 02 май № 59 – ФЗның 2 нче бүлеге 6 нчы статьясы таләпләрен үтәп, “Интернет” мәгълүмати - коммуникацион челтәренең җирле үзидарә органы рәсми сайтында урнаштырыла ала.”

2. Әлеге карар рәсми рәвештә кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы , шулай ук интернет мәгълүмати – коммуникацион

челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Кильдураз авыл җирлеге
Башлыгының урынбасары Ф.К. Шарафутдинов